СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОКУВАКСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ КУАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның 1 июне Иске Куак № 10

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 мартындагы 65-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 статьяны түбәндәге эчтәлекле унберенче яңа абзац белән тулыландырырга:

«гражданнарның бюджет процессында катнашуы»;

унберенче - ундүртенче абзацларны уникенче - унбишенче абзацлар дип санарга;

23 статьяда:

13 абзацта «муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «муниципаль гарантияләрдән килеп чыга» сүзләренә алмаштырырга;

19 абзацта «чагылдырылган муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «чагылдырылган муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган» сүзләренә алмаштырырга;

23 абзацны төшереп калдырырга;

27 статьяның 2 өлешендә «һәм Җирлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен раслау» сүзләреннән соң «инфраструктур проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

27 статьяның 3 өлешендә «һәм Җирлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен раслау» сүзләреннән соң «инфраструктур проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы, 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы
Совет рәисе И.Н Сушкова

ИНН 1625001105
КПП 164901001